*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 40**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Ирен-теш тартык авазларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [б], [п], [м], [w]
   **ә) [в], [ф]**
   б) [к], [г]
   в) [к], [ғ], [н], [h]

2. Ябык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бакчалар
   ә) мәктәбебез
   **б) дәфтәрләрнең**
   в) укучыдан

3. ***Куе*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) аз
   **ә) сыек**
   б) тирән
   в) сай

4. Искергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ашханә
   ә) флешмоб
   б) китап
   **в) мәктүп**

5. Кушылып языла торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) каз(үрдәк)
   ә) җир(җиләге)
   **б) юл(барыс)**
   в) исле(сабын)

6. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) зәңгәр

**ә) зәп-зәңгәр**
б) зәңгәррәк
в) зәңгәрсу

7. Үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
**а) шатланды**
ә) сөйләр
б) бел
в) утыралар

8. Боеру җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Балалар мәктәп бакчасында эшлиләр.
ә) Кыярлар өлгергән.
б) Агачларның яфраклары нинди төстә?
**в) Кошларның сайрауларын тыңлагыз.**

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Ялгызлык исемнәре **баш** хәрефтән языла. Авазларның әйтелешен язуда күрсәтү **транскрипция** дип атала. Сүзлекләр төзү турындагы фән **лексикография** дип атала. Парлы сүзләр һәрвакыт **сызыкча аша** языла. **Боерык** фигыльләр эш кушуны белдерә. Җөмләдә бер үк сорауга җавап биргән, бер үк сүзне ачыклаган сүзләр **тиңдәш** кисәкләр дип атала.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

*дым – төтен* *скорость – тизлек*
*паук – үрмәкүч* *экзамен – имтихан*

2. “Минем гаиләм” дигән темага 8 җөмләдән торган инша языгыз. **(14 балл)**